Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

18 январь 2023 ел | №2

Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 12.08.2021 ел, №24 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре"нә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 12.08.2021 ел, №24 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында"гы кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кагыйдәләрнең 26.3 статьясындагы таблицаның 4нче һәм 5нче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «2.1 | Шәхси торак төзелеше өчен | мин. – 400<br>макс. – 2000 | 3 этаж/18 м | 50 % | 5/3». |
| 2.2 | Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге) | Мин. – 400<br>Макс. - 2000 | 3 этаж/18 м | 40% | 5/3». |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге http://pravo.tatarstan.ru/saba адресы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча бастырып чыгарырга.

Җирлек башлыгы | Р.М. Хәсәнов